Республика Татарстан
Глава Верхне-Чершилинского
сельского поселения
Сармановского муниципального
района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районының
Югары Чыршылы авыл
җирлеге башлыгы

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

07.11.2023

№ 6

2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар итәм:

1.Түбән Чыршылы авылының Горький урамындагы 9-нчы номерлы йорт янында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2023 елның 17 ноябренә 11.00 сәгатьтә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Югары Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидларыннан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:

1) Түбән Чыршылы торак пунктында традицион җирләү урыннарын ремонтлау, төзекләндерү (зират өчен хуҗалык бинасы урнаштыру, төзү материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);

2) Түбән Чыршылы торак пуктында җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту (махсус техникага хезмәт күрсәтү МТЗ - 82.1 тракторы, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);

3) җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту (Түбәнге Чыршылы торак пунктында кышкы вакытта юлларны кардан чистарту);

4) янгынга каршы резервуарларны (янгын сүндерү сулыкларын), янгын сүндерү пирсларын (Түбән Чыршылы торак пунктында янгын сүндерү сулыклары төзү, төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү).

«ӘЙЕ «ЮК»

3.Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә http://pravo.tatarstan.ru һәм Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http:// sarmanovo.tatarstan.ru кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы И.Н. Камалетдинов